ГОСУДАРСТВЕННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Комитет по государственному строительству
и местному самоуправлению
420060, г. Казань, площадь Свободы, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
Дәүләт корылышы
һәм җирле үзидарә комитеты
420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1

Тел.: (843) 267-64-21, факс: (843) 292-91-68. E-mail: gosstr.gsrt@tatar.ru. Сайт: gossov.tatarstan.ru

7 июня 2022 № 1-134-6-ПК

На №__________ от__________

Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү турындагы мөрәҗәгатен карап, «Географик объектлар исемнәре турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны 2022 елның 24 июнендә 10 сәгатьтә билгеләргә.

Гавами тыңлауларны үткәрү урынын Татарстан Республикасы Әлки районының «Хузангай клуб-музее» муниципаль учреждениесе бинасы дип билгеләргә, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Сиктерме-Хузангай авылы, Майский урамы, 1А йорт.

2. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Хәбибуллин Альберт Галимҗан улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе;

Билалов Рәшит Әбрар улы – Әлки муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Ибраһимова Лиана Илгиз кызы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең конституциячел законнар бүлеге мөдире;

Мотыйгуллина Гөлшат Әмир кызы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире;

Толмачева Лилия Фаикъ кызы – Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча).

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Дәүләт корылышы һәм җирле
үзидарә комитеты рәисе А.Г. Хәбибуллин